**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Түбән Тархан авылы эчендәге юлларны төзекләндерү өчен ком һәм вак таш сатып алу;
- Түбән Тархан авылында кое төзү;
- Түбән Тархан авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, ятырткычлар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.М. Айзатуллов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлеге башлыгы** **А.М. Айзатуллов**